Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№3 (71)

Декабрь, 2025 нче ел

**Бу санда**

*Ел укытучысы* 2

*Математика – барлык фәннәр патшасы* 3

*Яңа – 2026 елны каршылап* 4

*Йолдызнамә – 2026* 4

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

*Гимназия яңалыклары - безнең рәсми сайтта https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym*

*Гимназия яңалыклары - социаль челтәрдә https://vk.com/gymnasiummus*




### Хөрмәтле укучылар һәм укытучылар!

Менә декабрьнең соңгы көннәренә дә аяк бастык. Тиздән календарьдагы иң күркәм, иң эчкерсез, күңелле бәйрәм - Яңа ел җитә. Әлбәттә инде без - укытучылар һәм укучылар өчен ул күңелле мәшәкатьләр бәйрәме. Чыршы бәйрәмнәре уздырасы, бүләкләр, яңа ел кучтәнәчләре әзерлисе бар. Шул мәшәкатьләр өстенә әле уңышлы гына чирек тәмамлыйсы...

Барыгызны да якынлашып килүче Яңа ел белән чын күңелдән котлыйм! Эшегездә, укуыгызда, тормышыгызда зур уңышлар юлдаш булсын! Ходай тәгалә саулык-сәламәтлектән аермасын, гаиләләребезгә тынычлык бирсен, кайгы-хәсрәт күрсәтмәсен. Яңа Ат елы укытучыларны укучыларының уңышлары белән сөендерсен.

Әлеге искиткеч һәм барыбыз да яраткан бәйрәм уңаеннан иң изге теләкләрне кабул итеп алыгыз. Яңа елны, туган һәр яңа көнне елмаеп, зур өметләр һәм хыяллар белән каршы алыгыз! Күңелегез саф, хисләрегез эчкерсез, хыялларыгыз якты һәм матур булсын. Бәйрәмнәрегез мөбәрәк, табыннарыгыз түгәрәк булсын!

***Гимназия директоры Мирзаянов Азат Фәрит улы***







### Ат елы “5”леләргә мул булсын!

2026 ел - үзең турында белдерергә, күптәнге хыялларны тормышка ашырырга һәм хәтта үз чикләүләрең аша «сикерергә» уңайлы вакыт. Иң мөһиме - үзегезгә чын күңелдән ышаныгыз, ул чагында сезне уңыш көтә.

Кытай мәдәниятендә бу ел көч, тизлек, тугрылык, намуслылык, максатка омтылуны гәүдәләндерә.

Ат һәрвакыт кеше янында булган: эштә дә, сәяхәттә дә, сугыш кырында да. Аны гравюраларда, фарфор вазаларда һәм тукымаларда сурәтләгәннәр. Ат фигурасы карьера үсешен, уңышны һәм алга китешне символлаштыра. Хәтта телдә дә аның образы нык урнашкан: «ма дао чэн гун» — «аттан соң уңыш» дигән гыйбарә максатка тиз ирешүне аңлата.

Ел уңыш китерсен өчен эчке күтәренкелек мөһим: искене җибәрегез, максатлар куегыз һәм ачык йөрәк белән киләчәккә барыгыз.

***“Тылсым+” газетасы редколлегиясе***

### Мәктәп укучыларының республика һәм бөтенроссия олимпиадаларының муниципаль этабы көндәлеге




Икенче чиректә укучыларыбыз республика һәм бөтенроссия олимпиадаларының муниципаль этабында катнаштылар. Олимпиадаларның муниципаль этабы тәмамланды, уңышларыбыз да шактый. 9 нчы в сыйныфы укучысы Айгильдина Зарина - 4 фәннән, 11 нче сыйныфтан Газетдинова Азалия - 3 фәннән, 7 нче б сыйныфыннан – Бариев Ислам, 8 нче а дан Әминова Айсылу, 11 нче сыйныфтан Хасанова Йолдызлар 2 шәр фәннән җиңү яуладылар.

Барлыгы, гимназия укучылары 31 җиңү һәм 143 призлы урынга лаек булдылар. Алда Бөтенрәсәй һәм республика турлары көтә.

## “ЕЛ УКЫТУЧЫСЫ - 2025” БӘЙГЕСЕ

**"Ел укытучысы - 2025" Бөтенрәсәй конкурсының муниципаль этабында гимназия укытучылары да катнашты.**

Бәйгедә катнашучылар дәрес уткәрүнең кызыклы формаларын, укучылар белән эшләүнең нәтиҗәле алымнарын, заманча технологияләрне педагогик эшчәнлектә куллану ысулларын күрсәттеләр.

"Ел укытучысы - 2025" конкурсының муниципаль тур җиңүчесе гимназиянең биология укытучысы Бариева Ләйсән Фәһәметдин кызы. Тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Гайсарова Динара Илнар кызы, физика укытучысы Әгъләмов Ринат Булат улы лауреат булдылар.

Башлангыч сыйныф укытучысы Әюпова Г.А., рус теле һәм әдәбияты укытучысы Ситдикова Р.Р. да бу бәйгедә көч сынаштылар.

Әлеге җиңүләр - укытучыларыбызның тырыш хезмәте, даими камилләшүе һәм үз һөнәрләренә чиксез мәхәббәте нәтиҗәсе.

Педагогларыбызны зур җиңүләре белән чын күңелдән котлыйбыз!






## “ЕЛ УКУЧЫСЫ - 2025” БӘЙГЕСЕ

**Традицион 4 нче сыйныф укучыларының "Ел укучысы - 2025" муниципаль конкурсының зона этабы гимназия базасында үтте.**

Гимназиядән әлеге бәйгедә 4 укучы катнашты: Хабибуллина Алия, Хөсәенов Айзат (4 нче а сыйныфы), Солтанова Сылу, Мөхәммәтова Камилә (4 нче б сыйныфы).

Нәтиҗәләр түбәндәгечә: 1 нче урында Хабибуллина Алия (укытучысы - Ермолаева Э.С.), 2 нче урында Солтанова Сылу (укытучысы - Мирзасалихова Г.Ш.)

Укучыларны һәм укытучыларны котлап, муниципаль этапта да уңышлы чыгыш ясауларын көтеп калабыз.



## МӘКТӘП КИТАПХАНӘЧЕЛӘРЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ ХАЛЫКАРА ФОРУМЫ

**2025 нче елның 11-12 нче декабрендә Мәскәүдә мәктәп китапханәчеләренең I Халыкара форумы узды.**

Чарада илебезнең 89 төбәгеннән 1000 педагог катнашты. Катнашучылар алдында дәүләт эшлеклеләре, мәгариф һәм китапханә эше өлкәсендәге белгечләр, танылган язучылар, актерлар һәм публицистлар чыгыш ясадылар.

Безнең гимназиядән финал турында педагог-китапханәче Солтанова Гөлшат Марс кызы катнашты.





## МӨМКИНЛЕКЛӘРНЕҢ ЧИГЕ ЮК: ИНВАЛИДЛАР ДЕКАДАСЫ


Инвалидлар декадасы уңаеннан гимназиядә ярминкә оештырылды. Бу чара алдан ук планлаштырылган иде, шунлыктан 1-9 нчы сыйныф укучылары барысы да актив булдылар. Сатучы урынында – укучылар үзләре. Аларга ярдәмгә укытучылар, ата-аналар килде. Балалар якты чырай, тәмле тел белән товарларын мактадылар. Өстәл тәмледән-тәмле тортлар, пироглар, печеньеларның төрледән-төрлесе, кабартмалар, чәк-чәктән сыгылып торды. Ярминкәдә алынмыйча калган бер товар да калмады, сатудан 168 572 сум акча керде.

Хәйрия марафонында барлыгы 201 822 сум акча җыелды. Җыелган акча мөмкинлекләре чикләнгән райондашларыбызга, балаларга тапшырылды.

Һәркемнең изгелеге меңе белән әйләнеп кайтсын!



# МАТЕМАТИКА – БАРЛЫК ФӘННӘР ПАТШАСЫ



**1 нче декабрь**

**Математика көне**

*Математика көне - Россиядә 1 декабрьдә билгеләп үтелә торган математикларның һөнәри бәйрәме. Бу көн рус математигы, Евклид булмаган геометрияне булдыручы Николай Лобачевскийның туган көненә багышланган. Математика көнен бәйрәм итү кысаларында бөтен ил буйлап мәгърифәтчелек һәм белем бирү чаралары уздырыла. Безнең гимназиядә дә укучылар өчен сыйныф сәгатьләре, викториналар, кызыклы дәресләр үткәрелде.*

*«Инфознайка» түгәрәге әгъзалары «Квадратные новости» исемле кызыклы мәктәп математика газетасын әзерләделәр, аның чыгарылышын математика көненә багышладылар. Бу проект балаларның талантларын күрсәтү өчен бик яхшы мәйданчык булды, чөнки һәр катнашучы саннар һәм формулалар дөньясы турында мавыктыргыч материаллар белән тулы якты басма булдыруга үз өлешен кертә алды.*

## Физика-математика алгарышы

10 нчы декабрь көнне гимназия базасында математика укытучыларының "Табигый-фәнни һәм математик грамоталылыкны формалаштыру" дигән республика семинар-стажировкасы узды. Семинарда математика, физика, биология, информатика укытучылары, район мәктәпләре директорлары, КФУның Психология һәм мәгариф институты Мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм камилләштерү Идел буе төбәкара үзәге директоры Шәйхелисламов Рәис Фалих улы катнашты. Семинар кысаларында башлангыч сыйныф укытучылары Фәхердинова Л.А., Галимәрдәнова З.Д., математика укытучылары Заялова Л.Н., Солтанова Л.Р. математика фәненән ачык дәресләр күрсәттеләр; биология укытучысы Бариева Л.Ф. биология дәресе, физика укытучысы Агләмов Р.Б. физика дәресе күрсәтте. Барлык дәресләр дә яхшы бәяләмәләр алды һәм укытучыларга сертификатлар тапшырылды.










## БУЛДЫРАСЫҢ, ӘМИР! (ӘҢГӘМӘ)



Дәүләтшин Әмир,
11 нче сыйныф укучысы

***Хәерле көн, Әмир! Сине математика буенча олимпиада да җиңүең белән котлыйм! Безгә дә сөйлә әле, син бу вакыйгага күпме әзерләндең?***

Хәерле көн! Мин математика фәненнән олимпиадага 8 нче сыйныфтан әзерләнә башладым һәм соңгы өч елда муниципаль этапта җиңүче булдым. 9, 10 нчы сыйныфларда республика этабы призеры булдым.

***Мондый ярышларда катна-шып, уңышка ирешү зур тырыш-лык сорый. Син ничек уйлыйсың, иң мөһим фактор нәрсә?***

Минемчә, иң мөһим фактор - тырышлык, фән белән кызыксыну, өстәмә эзләнү.


***Киләчәккә планнарың нинди? Фән белән шөгыльләнүне дәвам итәргә яки башка төрле юнәлеш сайларга уйламыйсыңмы?***

Олимпиадаларда катнашучыларга нинди киңәшләр бирер идең?

Темаларны игътибар белән өйрәнергә, укытучыларны тыңларга, материалны үзләштерү өчен өйдә өстәмә шөгыльләнергә киңәш итәм.

***Рәхмәт, Әмир төпле киңәшләрең өчен. Сиңа киләчәктә дә уңышлар, БДИларны уңышлы тапшыруыңны телибез.***

***Әңгәмәдәш***
***Замалова Зәринә***



## Бу кызык!

*– Үрмәкүчнең аякларын кеше кулындагы бармаклар санына тапкырлагыз.*

*– Иң яраткан билгегезне иң кечкенә икеурынлы санга тапкырлагыз.*

*– Бер елдагы барлык айлар санын Змея Горынычның башлары санына бүләргә.*

*– Буратино сүзендәге хәрефләр санын бөркетнең канатлары санына бүләргә.*

*– Кафеда һәр өстәлгә 8 алма һәм 6 банан куярга кирәк. 6 өстәлгә ничә җиләк куярга кирәк?*

## ЯҢА – 2026 ЕЛНЫ КАРШЫЛАП







## ЙОЛДЫЗНАМӘ – 2026



**Кучкар**

Нәрсәгә тотынсаң да, эшең уңышлы булыр. Аралашучанлыгыңны арттыр, дусларың күп булсын. Бу сыйфатың сиңа ел дәвамында барлык өлкәләрдә дә булышачак.

**Үгезбозау**

Кирелегеңне читкә куеп, яхшы укырга тырыш. Якыннарың турында да онытма. Аларга игътибарыңны кызганма. Сәламәтлегеңне кайгырт.

**Игезәкләр**

Җаваплылыктан курыкма. Үз дигәнеңә ирешәчәксең. Син бик сәләтле һәм позитив, шуңа да сине тирә-юньдәгеләр ярата. Ат елы яңа танышлар бүләк итәр.

**Кысла**

Яңа шөгыль үзләштерү өчен менә дигән ел! Кыюрак бул, син үзең уйлаганнан да сәләтлерәк. Мөмкинлекләр күп булачак, аларны кулдан ычкындырма. Күбрәк саф һавада йөр.

**Арыслан**

Хыялларыңны чынга ашыра алачаксың. Үз-үзеңә ышанычың зур. Шуңа күрә уңышка җиңел ирешерсең. Әмма ашыгыч карарлар кабул итмәскә кирәк.

**Кыз**

Син – бик тырыш һәм таләпчән кеше. Укуда уңышлар ялаячаксың. Әмма ял турында да уйларга кирәк. Гаилә белән чит илгә сәяхәт көтелергә мөмкин.

**Үлчәү**

Һәр сынауда мөмкинлек күрерсең. Озак уйлама, башыңа килгән фикерне чынга ашыр, юкса аның хыял булып кына калуы ихтимал. Икеләнүеңнән туктарга кирәк.

**Чаян**

Сер капчыгыңны яхшылап бәйләп тот. Якыннарың белән аралашканда сабырлык күрсәт. Үҗәтлегең һәм чаялыгың максатларыңа ирешкәндә ярдәм итәр.

**Укчы**

Иҗади шөгыльләр сайла. Таетрларга, музейларга йөрү файдага булыр. Нәрсә дә булса килеп чыкмаса, күңелеңне төшермә. Ел ахырына уйлаганнарың чынга ашар.

**Кәҗәмөгез**

Спортка өстенлек бир. Өлкән яшьтәге туганнарыңны игътибарсыз калдырма. Кирәк вакытта якыннарыңнан ярдәм сорарга кыенсынма. Максатчан бул!

**Сукояр**

Башкалардан аерылып торырга курыкма. Тәвәккәл булсаң, сине ерактан ук күреп алачаклар. Киенү стилеңне, чәчләреңне үзгәртеп кара.

**Балык**

Нечкә күңелле булуыңны тискәре сыйфат дип санама. Ул синең игелеклек һәм ихлас икәнлегеңне күрсәтә. Волонтерлык белән шөгыльләнерсең.


ТЫЛСЫМ+

Декабрь, 2025 нче ел

№3 (71)

Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.

**Мөхәррир:** Замалова Зәринә
**Корректорлар:** Хәйруллина Диләрә
**Корреспондентлар:** Насырова Мәрьям, Фәхрәзиева Алинә
**Дизайнер:** Мостафина Рәйлә
**Компьютерда җыючылар:** Вагыйзов Айзат, Сәләмов Наил

*2014 нче елдан айга бер тапкыр нәшер ителә*

**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim2014@yandex.ru
**Формат:** А4 (А3)
**Тираж:** 100